**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Яңа Спас авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

**№ 13** **29 декабрь 2025 ел.**

**«Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлеге советы 2013 елның 19 декабрендәге 87 номерлы «Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 ноябрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлеге Уставы нигезендә, Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлегенең 19.12.2013 № 87 карары белән расланган Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәнең 8 пунктындагы 34 абзацы (2015 елның 18 мартындагы 128, 2018 елның 5 июнендәге 110, 2019 елның 5 ноябрендәге 158, 2021 елның 16 июле № 32, 07.06.2022 №61, 13.11.2023 №102, 27.12.2024 № 147 кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының 221 статьясы нигезендә билгеләнгән тәртиптә бюджет сметасын төзи, раслый һәм алып бара;».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) белән, җирлекнең торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегенә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе Танчук Н.В.